Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«25» ноябрь 2021 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- юлларны карап тоту, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәттә торак пункт чикләрендәге юлларда алга таба вак таш җәю өчен грейдер белән тигезләү һәм тыгызлап нигезен күтәрү буенча хезмәтләр;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юл өслеге профилен үзгәртеп вак таш сатып алу, вак таш түшәү өчен хезмәт күрсәтүләр;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге православие зиратын төзекләндерү һәм тирәсен тоту

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов